Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

РЕШЕНИЕ

КАРАР

17.12.2025 Менделеевск ш. № 21

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының «Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә акчалата бүләкләүләр, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында "2022 елның 30 декабрендәге 169 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, рәисләр, рәис урынбасарлары, контроль-хисап органнары аудиторлары, муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында “2018 елның 28 мартындагы 182 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында" 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы карарына таянып,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи оклады күләмен авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләменә тапкырлы күләмендә «15 389» санын «16 928» сумга алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының «Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә акчалата бүләкләүләр, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында "2022 елның 30 декабрендәге 169 нчы номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

2.1 Карарның 1 нче кушымтасында "Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә акчалата түләү күләмнәре" таблицасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**МУНИЦИПАЛЬ ВАЗЫЙФАЛАРНЫ ДАИМИ НИГЕЗДӘ БИЛӘҮЧЕ ЗАТЛАРГА, КОНТРОЛЬ-ХИСАП ОРГАНЫ РӘИСЕНӘ АКЧАЛАТА ТҮЛӘҮ КҮЛӘМНӘРЕ**

| Вазифа исемнәре | Акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 8 төркем | 9 төркем | 11 төркем | 12 төркем |
| Муниципаль район Башлыгы | 44 814 | | | |
| Муниципаль район Башлыгы урынбасары | 40 334 | | | |
| Контроль-хисап органы рәисе | 40 334 | | | |

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://prav.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында ttp://mendeleevsk.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Район Совет рәисе Р.Р.Искәндәров